**МИНИСТЕРСТВО ЭКОЛОГИИ И ПРИРОДНЫХ РЕСУРСОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЭКОЛОГИЯ ҺӘМ ТАБИГАТЬ РЕСУРСЛАРЫ МИНИСТРЛЫГЫ**

**ПРИКАЗ** Казан ш. **БОЕРЫК**

09.07.2019 715-п

Җир кишәрлеген авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрдән башка категориягә күчерүне килештерү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында

Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының норматив хокукый актларын гамәлдәге законнарга туры китерү максатларында боерык бирәм:

1. Җир кишәрлеген авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрдән башка категориягә күчерүне килештерү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең кушымтада бирелгән административ регламентын (алга таба – Регламент).

2. Җир ресурсларын саклау бүлегенә (Л.Ф.Мөбәракшина) югарыда аталган Регламентка ярашлы рәвештә эшләрнең башкарылуын тәэмин итәргә.

3. Хокукый тәэминат бүлегенә (А.Е.Никулин) шушы боерыкның дәүләт теркәвенә алу өчен Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына җибәрелүен тәэмин итәргә.

4. Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының «Җир кишәрлеген авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрдән башка категориягә күчерүне килештерү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2013 елның 19 ноябрендәге 670-п номерлы, «Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының 2013 елның 19 ноябрендәге 670-п номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының җир кишәрлеген авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрдән башка категориягә күчерүне килештерү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү хакында» 2014 елның 21 февралендәге 113-п номерлы, «Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының 2013 елның 19 ноябрендәге 670-п номерлы боерыгы белән расланган Җир кишәрлеген авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрдән башка категориягә күчерүне килештерү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү хакында» 2016 елның 7 июлендәге 634-п номерлы боерыкларын көчен югалткан дип танырга.

5. Әлеге боерык үтәлешен тикшереп тору буенча министр урынбасары Ф.Ф.Шакировны җаваплы итеп билгеләргә.

Министр в.б. Ф.Ф.Шакиров

Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының 2019 елның 9 июлендәге 715-п номерлы боерыгы белән расланды

Җир кишәрлеген авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрдән башка категориягә күчерүне килештерү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламенты

## 1. ГОМУМИ НИГЕЗЛӘМӘЛӘР

1.1. Әлеге Регламент җир кишәрлеген авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрдән башка категориягә күчерүне килештерү буенча дәүләт хезмәте (алга таба – дәүләт хезмәте) күрсәтүнең стандартын һәм тәртибен билгели.

1.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү буенча мөрәҗәгать итүче булып дәүләт хезмәтен алучы яки аның законлы вәкиле йә дәүләт хезмәтен алучы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә рәсмиләштерелгән ышанычнамә нигезендә эш кылуга вәкаләт бирелгән зат (алга таба – мөрәҗәгать итүче) тора.

1.3. Дәүләт хезмәте Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы (алга таба – Министрлык) тарафыннан күрсәтелә.

1.3.1. Министрлык урнашкан урын: Казан ш., Павлюхин ур., 75 й.

Дәүләт хезмәтен күрсәтү мәсьәләләре буенча документларны һәм мөрәҗәгатьләрне җибәрү өчен Министрлыкның почта адресы: 420049, Татарстан Республикасы, Казан ш., Павлюхин ур., 75 й.

Министрлыкның эш графигы: көн саен, шимбә һәм якшәмбедән кала, дүшәмбе-пәнҗешәмбе 9.00 сәгатьтән алып 18.00 сәгатькә кадәр, җомга 9.00 сәгатьтән алып 16.45 сәгатькә кадәр, төшке аш: 12.00 сәгатьтән 12.45 сәгатькә кадәр.

Гаризалар кабул итү графигы: көн саен, шимбә һәм якшәмбедән тыш, Министрлыкның эш көннәрендә.

Җәмәгать транспортында «Павлюхин» тукталышына кадәр килергә кирәк:

№ 2, 4, 5, 12, 25, 31, 37, 43, 47, 69, 69а, 74, 74а, 77 автобуслар;

троллейбуслар: №№ 6, 8, 12;

метро, «Сукно бистәсе» станциясенә кадәр.

Кертү рөхсәт кәгазе һәм (яки) шәхесне таныклый торган документ ярдәмендә.

1.3.2. Министрлыкның җир ресурсларын саклау бүлегенең (алга таба – Бүлек) белешмә телефоннары: (843) 267-68-36, 264-53-09.

1.3.3. Министрлыкның «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге «Татарстан Республикасы рәсми порталы» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасы составына керә торган рәсми сайты адресы (алга таба, тиешенчә – Министрлыкның рәсми сайты һәм «Интернет» челтәре): http://eco.tatarstan.ru, электрон почта адресы: eco@tatar.ru.

1.3.4. Дәүләт хезмәте турында, шулай ук Министрлык урнашкан урын һәм аның эш графигы турында мәгълүмат түбәндәгечә алынырга мөмкин:

1) дәүләт хезмәте турында визуаль һәм текстлы мәгълүматны үз эченә алган, Министрлыкның мөрәҗәгать итүчеләр белән эшләү бүлмәләрендә урнашкан дәүләт хезмәте турындагы мәгълүмат стендлары аша;

2) «Интернет» челтәре аша:

Министрлыкның рәсми сайтында (http://www.eco.tatarstan.ru);

Татарстан Республикасының Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр порталында (http://uslugi.tatar.ru);

Дәүләт хезмәтләренең һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) бердәм порталында (http://www.gosuslugi.ru/);

3) Министрлыкка телдән мөрәҗәгать иткәндә (шәхсән яки телефон аша);

4) Министрлыкка язмача мөрәҗәгать иткәндә (шул исәптән электрон документ рәвешендә).

1.3.5. Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә дәүләт хезмәте күрсәтү мәсьәләләренә бәйле мәгълүматлар Бүлек белгече тарафыннан Министрлыкның рәсми сайтында һәм Министрлык бүлмәләрендә урнаштырылган мәгълүмат стендларында урнаштырыла.

Мәгълүмат стендларында урнаштырыла торган мәгълүмат әлеге Регламент-ның 1.3, 1.4, 2.1, 2.3, 2.4, 2.5, 2.8, 2.10, 2.11, 5.1 пунктларында (пунктчаларында) булган дәүләт хезмәте турында белешмәләрне үз эченә ала.

1.4. Дәүләт хезмәте түбәндәгеләргә нигезләнеп күрсәтелә:

Россия Федерациясе Җир кодексы (алга таба – РФ Җир кодексы);

Россия Федерациясе Әәһәр төзелеше кодексы (алга таба – РФ Шәһәр төзелеше кодексы);

Россия Федерациясе Су кодексы (алга таба – РФ Су кодексы);

Россия Федерациясе Урман кодексы (алга таба – РФ Урман кодексы);

«Җир асты байлыклары турында» 1992 елның 21 февралендәге 2395-1 номерлы Россия Федерациясе законы (алга таба – 2395-1 номерлы РФ законы) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 1995, № 10, 823 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Табигый дәвалау ресурслары, дәвалау-савыктыру урыннары һәм курортлары турында» 1995 елның 23 февралендәге 26-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 26-ФЗ номерлы Федераль закон) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 1995, № 9, 713 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Махсус саклана торган табигать территорияләре турында» 1995 елның 14 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 33-ФЗ номерлы Федераль закон) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 1995, № 12, 1024 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Хайваннар дөньясы турында» 1995 елның 24 апрелендәге 52-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 1995 елның 24 апрелендәге 52-ФЗ номерлы Федераль закон) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 1995, № 17, 1462 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Экологик экспертиза турында» 1995 елның 23 ноябрендәге 174-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 174-ФЗ номерлы Федераль закон) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 1995, № 48, 4556 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Халыкның радиация куркынычсызлыгы турында» 1996 елның 9

гыйнварындагы 3-ФЗ номерлы Федераль закон (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 1996, № 3, 141 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Халыкның санитар-эпидемиологик иминлеге турында» 1999 елның 30 мартындагы 52-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 1999 елның 30 мартындагы 52-ФЗ номерлы Федераль закон) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 1999, № 14, 1650 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Әйләнә-тирәлекне саклау турында» 2002 елның 10 гыйнварындагы 7-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – № 7-ФЗ Федераль закон) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2002, № 2, 133 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Җирләрне яки җир кишәрлекләрен бер категориядән икенчесенә күчерү турында» 2004 елның 21 декабрендәге 172-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 172-ФЗ номерлы Федераль закон) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2004, № 52, 5276 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Кадастр эшчәнлеге турында» 2007 елның 24 июлендәге 221-ФЗ номерлы Федераль закон (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2007, № 31, 4017 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 210-ФЗ номерлы Федераль закон), (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2010, № 31, 4179 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Электрон имза турында» 2011 елның 6 апрелендәге 63-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 63-ФЗ номерлы Федераль закон) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2011, № 15, 2036 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Җитештерү процессларын гамәлгә ашырганда, шулай ук транспорт магистральләрен, торбаүткәргечләрне, элемтә һәм электр тапшыру линияләрен файдаланганда хайваннар дөньясы объектлары һәлак булуын чикләү таләпләрен раслау турында» 1996 елның 13 августындагы 997 номерлы карары (алга таба – РФ Хөкүмәтенең 997 номерлы карары) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 1996, № 37, 4290 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Атом-төш җайланмаларын, радиация чыганакларын һәм аларны саклау пунктларын урнаштыру һәм төзү турында карарлар кабул итү кагыйдәләре турында» 1997 елның 14 мартындагы 306 номерлы карары (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 1997, № 12, 1442 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Файдалы казылма ятмаларын эшкәртүнең техник проектларын һәм файдалы казылма төрләре һәм җир асты байлыкларыннан файдалану төрләре буенча җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалануга бәйле эшләр башкаруга бүтән проект документларын әзерләү, килештерү һәм раслау турында нигезләмә раслау хакында» 2010 елның 3 мартындагы 118 номерлы карары (алга таба – РФ Хөкүмәтенең 118 номерлы карары) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2010, № 10, 1100 ст.) (кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Хөкүмәте «Җир асты су объектларын саклау кагыйдәләрен раслау турында» 2016 елның 11 февралендәге 94 номерлы карары

(алга таба – РФ Хөкүмәтенең 94 номерлы карары) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2016, № 8, 1115 ст.);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Җирләргә рекультивация һәм консервация үткәрү турында» 2018 елның 10 июлендәге 800 номерлы карары (алга таба – РФ Хөкүмәтенең 800 номерлы карары) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2018, № 29, 4441 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Баш дәүләт санитария табибының 2001 елның 25 июлендәге 19 номерлы карары белән расланган «Җир асты суларын пычранудан саклауга карата гигиена таләпләре. СП 2.1.5.1059-01» санитария кагыйдәләре (алга таба – СП 2.1.5.1059-01)(Федераль башкарма хакимият органнары норматив актлары бюллетене, 2001, № 38);

Россия Федерациясе Баш дәүләт санитария табибының 2002 елның 14 мартындагы 10 номерлы карары белән расланган «Эчү өчен билгеләнгән су белән тәэмин итү чыганакларын һәм сууткәргечләрне санитар саклау зоналары. СанПиН 2.1.4.1110-02» санитария кагыйдәләре һәм нормалары (алга таба – СанПиН 2.1.4.1110-02) (Федераль башкарма хакимият органнары норматив актлары бюллетене, 2002, № 19, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының 2016 елның 30 декабрендәге 1034/пр номерлы боерыгы белән расланган «СП 42.13330.2016. Шәһәр төзелеше. Шәһәр һәм авыл җирлекләрен планлаштыру һәм аларда биналар төзү. СНиП 2.07.01-89* актуальләштерелгән редакциясе» кагыйдәләр җыелмасы (алга таба – СП 42.13330.2016) (Норматив, методик һәм бертип проект документациясе турында мәгълүмат бюллетене, 2017, № 8, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«ГОСТ 17.1.3.06-82 (СТ СЭВ 3079-81). ССР берлеге дәүләт стандарты. Табигатьне саклау. Гидросфера. Җир асты суларын саклауга карата гомуми таләпләр» дәүләт стандарты (алга таба – ГОСТ 17.1.3.06-82) (СССР Госстандартының 1982 елның 25 мартындагы 1244 номерлы карары белән гамәлгә кертелгән);

«17.5.3.04-83 (СТ СЭВ 5302-85). ССР берлеге дәүләт стандарты. Табигатьне саклау. Җирләр. Җирләрне рекультвацияләүгә карата гомуми таләпләр» дәүләт стандарты (алга таба – ГОСТ 17.5.3.04-83) (СССР Госстандартының 1983 елның 30 мартындагы 1521 номерлы карары белән гамәлгә кертелгән);

«17.4.3.02-85 (СТ СЭВ 4471-84). ССР берлеге Дәүләт стандарты. Табигатьне саклау. Туфраклар. Җир эшләрен башкарганда туфракның уңдырышлы катламын саклауга карата таләпләр» дәүләт стандарты (алга таба – ГОСТ 17.4.3.02-85) (СССР Госстандартының 1985 елның 5 маендагы 1294 номерлы карары белән гамәлгә кертелгән);

кулланма документ РД 153-39.2-080-01 «Автотэмин итү станцияләрен техник эксплуатацияләү кагыйдәләре», РФ Энергетика министрлыгының 2001 елның 1 августындагы 229 номерлы боерыгы белән расланган (алга таба – РД 153-39.2-080-01) (Вестник Госэнергонадзора, 2002, № 1, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Татарстан Республикасы Җир кодексы;

Татарстан Республикасы Экология Кодексы;

«Җир асты байлыклары турында» 1992 елның 25 декабрендәге 1722-XII номерлы Татарстан Республикасы законы (алга таба – 1722-XII номерлы ТР Законы)(Татарстан Республикасы Дәүләт Советы җыелма басмасы, 2000, № 2, 43 ст. кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә җитештерү процессларын гамәлгә ашырганда, шулай ук транспорт магистральләрен, үткәргеч торбаларны, элемтә һәм электр тапшыру линияләрен файдаланганда хайваннар дөньясы объектлары үлүне булдырмый калу буенча таләпләр турында» 2000 елның 15 сентябрендәге 669 номерлы карары (алга таба – Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 669 номерлы карары) (Татарстан Республикасы законнары җыентыгы, 2018, № 15, 0547 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы мәсьәләләре» 2005 елның 06 июлендәге 325 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы турында нигезләмә (алга таба – Нигезләмә), («Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм республика башкарма хакимият органнары норматив актлары җыентыгы» журналы, 2005, № 28, 0654 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Авыл хуҗалыгы әһәмиятендәге җирләрдән җир кишәрлеген башка категориягә күчерү турындагы үтенечнамә формасын һәм аңа теркәлә торган документлар составын раслау хакында» 2006 елның 25 октябрендәге 523 нномерлы карары (алга таба – Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 523 нномерлы карары) («Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм республика башкарма хакимият органнары норматив актлары җыентыгы» журналы, 2006, № 41-42, 1061, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү хакында» 2010 елның 02 ноябрендәге 880 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибе (алга таба – Тәртип) («Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм республика башкарма хакимияте органнары норматив актлары җыентыгы» журналы, 2010, № 46, 2144 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары тарафыннан күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган һәм дәүләт хезмәтләре күрсәтүдә катнашучы оешмалар күрсәтә торган хезмәтләр исемлеген раслау турында» 2011 елның 13 августындагы 675 нномерлы (алга таба – Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 675 нномерлы карары) («Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары җыентыгы» журналы, 2011, № 39, 1928 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып,);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә үзләренә бүлеп бирелгән тау бүлемтекләре чикләрендә файдалы казылмаларны разведкалау һәм чыгару белән шөгыльләнүче яисә берләштерелгән лицензия буенча файдалы казылмаларны геологик өйрәнүне, разведкалауны һәм чыгаруны гамәлгә ашыручы җир асты байлыкларыннан файдаланучылар тарафыннан шәхси производство һәм технологик ихтыяҗлар өчен гомумтаралган файдалы казылмалар чыгару тәртибен раслау турында» 2011 елның 21 декабрендәге 1042 номерлы карары (алга таба – ТР Министрлар Кабинетының 1042 номерлы карары) («Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм республика башкарма хакимияте органнары норматив актлары җыентыгы» журналы, 2012, № 4, 0120 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә җир кишәрлекләре милекчеләре, җирдән файдаланучылар, җир хуҗалары һәм җир кишәрлекләрен арендага алучылар тарафыннан гомумтаралган файдалы казылмалар чыгару, җир асты корылмаларын төзү һәм көнкүреш коеларын һәм скважиналарын ясау тәртибен раслау турында» 2012 елның 29 февралендәге 171 номерлы карары (алга таба – ТР Министрлар Кабинетының 171 номерлы карары) («Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм республика башкарма хакимияте органнары норматив актлары җыентыгы» журналы, 2012, № 26, 0859 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 6 февралендәге 152-р номерлы күрсәтмәсе (алга таба – ТР МКның 152-р номерлы күрсәтмәсе) («Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм республика башкарма хакимияте органнары норматив актлары җыентыгы» журналы, 2013, № 14, 0524 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Биологик ресурслар буенча дәүләт комитеты мәсьәләләре» 2017 елның 15 декабрендәге 996 номерлы карары белән (Татарстан Республикасы законнары җыентыгы, 2017, № 95, 3544 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып).

1.5. Бу регламентта түбәндәге терминнар һәм билгеләмәләр кулланыла:

техник хата – дәүләт хезмәтен күрсәтүче орган тарафыннан җибәрелгән һәм документка (дәүләт хезмәте нәтиҗәсендә) кертелгән белешмәләрнең, белешмәләр кертүгә нигез булган документлардагы белешмәләрнең ярашсызлыгына китергән хата (язу, басма хата, грамматик яки арифметик хата);

дәүләт хезмәтләрен һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күпфункцияле үзәкнең читтән торып эшләү урыны – дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күпфункцияле үзәкнең «Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күпфункцияле үзәкләр эшчәнлеген оештыру кагыйдәләрен раслау турында» 2012 елның 22 декабрендәге 1376 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары белән расланган Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күпфункцияле үзәкләр эшчәнлеген оештыру кагыйдәләренең 34 пункты нигезендә Татарстан Республикасының шәһәр яки муниципаль районы (шәһәр округы) авыл җирлегендә булдырылган территориаль аерымланган структур бүлекчәсе (офисы);

дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза (алга таба – гариза) – мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәтен күрсәтү турында 210-ФЗ номерлы федераль законның 2 статьясының 1 пунктында каралган гарызнамәсе. Гариза әлеге Регламентның 2.5 пунктында каралган мәгълүматларны күрсәтеп, ирекле формада төзелә.

## 2. ДӘҮЛӘТ ХЕЗМӘТЕН КҮРСӘТҮ СТАНДАРТЫ

| Дәүләт хезмәте күрсәтү стандартына карата таләпнең аталышы | Стандартка карата таләпләр эчтәлеге | Дәүләт хезмәтен яки таләп билгели торган норматив акт |
|---|---|---|
| 2.1. Дәүләт хезмәтенең аталышы | Авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрдән җир кишәрлеген башка категориягә күчерүне килештерү | РФ Җир кодексының 8, 39.1, 39.9, 39.15, 78 статьялары;<br>172-ФЗ номерлы Федераль законның 2, 7 статьялары;<br>Нигезләмәнең 3.3.9 пункты;<br>523 номерлы ТР МК карары |
| 2.2. Дәүләт хезмәтен турыдан-туры күрсәтүче башкарма хакимият органының аталышы | Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы | 172-ФЗ номерлы Федераль законның 2 статьясы;<br>Нигезләмәнең 3.3.9 пункты;<br>523 номерлы ТР МК карары |
| 2.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсенә тасвирлама | Авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрдән җир кишәрлеген башка категориягә күчерүне килештерү турында бәяләмә.<br>Авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрдән җир кишәрлеген башка категориягә күчерүне килештерүдән баш тарту турында бәяләмә. | РФ Җир кодексының 39.15 статьясы;<br>172-ФЗ номерлы Федераль законның 3, 4 статьялары;<br>523 номерлы ТР МК карары |
| 2.4. Дәүләт хезмәтен күрсәтү чоры, шул исәптән дәүләт хезмәтен күрсәткәндә катнашучы оешмаларга мөрәҗәгать итү зарурлыгын исәпкә алып, Россия Федерациясе законнарында | Җир кишәрлеген авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрдән башка категориягә күчерүне килештерү буенча Министрлык бәяләмәсе – гариза кергән көннән алып җиде эш көне эчендә. Җир кишәрлеген авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрдән башка категориягә күчерүне килештерүдән баш тарту турында Министрлык бәяләмәсе – гариза | 523 номерлы ТР МК карары |

| | |
|---|---|
| туктатып тору мөмкинлеге каралган очракта, дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору чоры | кергән көннән алып җиде эш көне эчендә.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтү чорын туктатып тору каралмаган |
| 2.5. Закон актлары яисә бүтән норматив хокукый актлар нигезендә дәүләт хезмәтен, шулай ук дәүләт хезмәтен күрсәтү буенча зарури һәм мәҗбүри булган хезмәтләрне күрсәтү өчен зарури булган, мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылырга тиешле документларның тулы исемлеге, аларны, шул исәптән электрон рәвештә, мөрәҗәгать итүче тарафыннан алу ысуллары, аларны тапшыру тәртибе | Җир кишәрлеген авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрдән башка категориягә күчерү буенча бәяләмәләр бирүгә гариза (әлеге Регламентка 1 нче кушымта).<br>Гаризага түбәндәгеләр теркәлә:<br>1. Гариза бирүченең шәхесен таныклый торган документлар күчермәләре (гариза бирүчеләр – физик затлар өчен).<br>2. Ышаныч кәгазе (гаризага мөрәҗәгать итүченең вәкиле имза куйган очракта).<br>3. Авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге соралган җирләрне 1:25000 яисә 1:10000 масштабында күрсәтеп, сорала торган җир кишәрлекләренең чикләрен, торак пунктларның чикләрен һәм аларның атамаларын, җирләрнең төрләрен, гидрография элементларын һәм автомобиль юллары чикләрен күрсәтеп, планлы-картографик материал.<br>Дәүләт хезмәте алу буенча гариза бланкын мөрәҗәгать итүче Министрлыкка шәхсән мөрәҗәгать иткәндә алырга мөмкин. Бланкның электрон рәвеше Министрлыкның рәсми сайтында урнаштырылган.<br>Гариза һәм аңа теркәлә торган документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан кәгазьдә түбәндәге ысулларның берсе аша тапшырылырга (җибәрелергә) мөмкин: |

| | |
|---|---|
| | шәхсән (ышанычнамә нигезендә мөрәҗәгать итүче исеменнән гамәл кылучы зат тарафыннан);<br>кулга тапшыру турында тамгасы белән почта аша заказлы хат итеп.<br>Гариза белән документлар шулай ук мөрәҗәгать итүче тарафыннан көчәйтелгән электрон имза белән имзаланган электрон документ рәвешендә гомуми файдаланудагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәре, шул исәптән «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәре яки Татарстан Республикасының Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша да тапшырылырга (җибәрелергә) мөмкин |
| 2.6. Норматив хокукый актлар нигезендә дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури булган, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм бүтән оешмалар карамагындагы һәм мөрәҗәгать итүче аларны тапшырырга хокуклы булган документларның тулы исемлеге, шулай ук, шул исәптән электрон рәвештә, мөрәҗәгать итүче тарафыннан аларны алу ысуллары, аларны тапшыру тәртибе; әлеге документлар белән эш итүче дәүләт органы, җирле үзидарә органы яисә оешма | Ведомствоара хезмәттәшлек каналлары аша түбәндәге мәгълүматлар алына:<br>1. Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрыннан җир кишәрлегенә белешмәләр (Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә).<br>2. Җир кишәрлегендә төбәк әһәмиятендәге махсус саклана торган табигать территорияләре һәм дәүләт табигый тыюлыклары булуы турында мәгълүмат (Татарстан Республикасының Биологик ресурслар буенча дәүләт комитеты).<br>3. Җир кишәрлеген бирүне алдан килештерү турында вәкаләтле җирле үзидарә органы карары (әгәр җир кишәрлеге дәүләт мөлкәтендә яисә муниципаль мөлкәттә торган җирләрдән җир кишәрлеген оештыру яки аның чикләрен ачыклау зарурлыгы булганда Россия Федерациясе Җир кодексының 39.15 |

| | |
|---|---|
| | статьясының 1 пунктының 6 пунктчасында күрсәтелгән нигезләр буенча бирелгән очракта), кәгазьдә әзерләнгән җир кишәрлегенең урнашу схемасы теркәп, әгәр җир кишәрлеген төзергә кирәк булса һәм мондый җир кишәрлеген оештыру күздә тотылган чикләрдәге территорияне межалау проекты булмаса.<br>Җир кишәрлеген җир асты байлыкларыннан файдалану максатларында күчерү очрагында – җитәкче яисә аның тарафыннан моңа вәкаләт бирелгән затның имзасы һәм җир асты байлыкларыннан файдаланучы булап торучы оешма мөһере (Россия Федерациясе законнарында мөһергә ия булу йөкләмәсе билгеләнгән очракларда) белән таныкланган түбәндәгеләрнең күчермәләре:<br>– җир асты байлыкларыннан файдалануга лицензия (Идел буе федераль округы буенча җир асты байлыкларыннан файдалану департаментының Татарстан Республикасы буенча геология һәм лицензияләү бүлеге);<br>– планлы-картографик материалга бүлеп бирелгән тау чикләрен (терәк, параметр, структур, эзләү, бәяләү һәм разведка скважиналарын урнаштырудан тыш) төшереп, тау бүлеп бирү акты (Экологик, технологик һәм атом күзәтчелеге буенча федераль хезмәтнең Идел буе идарәсе (Ростехнадзор)).<br>Мөрәҗәгать итүче шушы пункттагы белешмәләрдән торучы документларны, шул исәптән мөмкинлек булганда электрон рәвештә, тапшырырга |

| | |
|---|---|
| | хокуклы.<br>Югарыда күрсәтелгән белешмәләрдән торучы документларның мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылмавы мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тарту өчен нигез була алмый.<br>Мөрәҗәгать итүче тапшырырга хокуклы булган документларны алу ысуллары һәм тапшыру тәртибе шушы Регламентның 2.5 пунктында билгеләнде.<br>Мөрәҗәгать итүчедән югарыда саналган, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм бүтән оешмалар карамагында булган документларны, шулай ук кабул итүдән яисә дәүләт хезмәтен яки муниципаль хезмәтне күрсәтүдән беренче мәртәбә баш тартканда булмавы һәм (яки) дөрес булмавы күрсәтелмәгән, дәүләт хезмәтен яки муниципаль хезмәтне күрсәтү өчен кирәкле документларны таләп итү тыела, 210-ФЗ номерлы Федераль законның 7 статьясының 1 өлешендәге 4 пунктында «а»-»г» пунктчаларында санап үтелгән очраклардан тыш |
| 2.7. Дәүләт хезмәте күрсәтү буенча, норматив хокукый актларда каралган очракларда, алар белән килештерү таләп ителә торган һәм бу гамәл дәүләт хезмәтен күрсәтүче башкарма хакимият органы тарафыннан гамәлгә ашырыла торган дәүләт хакимияте органнарының һәм аларның | Дәүләт хезмәтен килештерү таләп ителми |

| | |
|---|---|
| структур бүлекчәләренең исемлеге | |
| 2.8. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури документларны кабул итүдән баш тарту нигезләренең тулы исемлеге | Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури документларны кабул итүдән баш тарту нигезләре каралмаган |
| 2.9. Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору яисә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту нигезләренең тулы исемлеге | Дәүләт хезмәтен күрсәтүне туктатып тору нигезләре юк.<br>Дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләр юк |
| 2.10. Дәүләт хезмәтен күрсәткән өчен алына торган дәүләт пошлинасын яки бүтән төрле түләүне алу тәртибе, аның күләме һәм алыну нигезләре | Дәүләт хезмәте түләүсез нигездә күрсәтелә |
| 2.11. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм зарури булып саналучы хезмәтләрне күрсәтү өчен түләү алу тәртибе, аның күләме һәм алу нигезләре, мондый түләү күләмен хисаплау методикасы турында мәгълүматны да кертеп | Зарури һәм мәҗбүри хезмәтләр күрсәтү күздә тотылмый |
| 2.12. Дәүләт хезмәтен күрсәтү турындагы гаризаны тапшырганда яисә мондый хезмәтләр күрсәтүнең нәтиҗәләрен алганда чиратта | Дәүләт хезмәтен күрсәтү турында гаризаны тапшырганда һәм мондый хезмәтләр күрсәтүнең нәтиҗәсен алганда чират көтүнең максималь вакыты – 15 минут тәшкил итә.<br>Дәүләт хезмәте алучы аерым категорияләр өчен |

| | |
|---|---|
| көтүнең максималь вакыты | чират билгеләнмәгән. |
| 2.13. Мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәтен күрсәтү турындагы гарызнамәсен, шул исәптән электрон рәвештә теркәү вакыты | Гариза кергән көнне.<br>Гариза электрон формада ял (бәйрәм) көнендә килгән очракта – килгән көненнән соңгы эш көнендә |
| 2.14. Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган биналарга, мөрәҗәгать итүчеләрнең көтү һәм аларны кабул итү урыннарына карата, шул исәптән аталган объектларның инвалидларны социаль яклау турында Россия Федерациясе законнары нигезендә инвалидлар өчен файдалану мөмкинлеген тәэмин итүгә, мондый хезмәтләр күрсәтү турында визуаль, текстлы һәм мультимедияле мәгълүматлар урнаштыруга һәм рәсмиләштерүгә карата таләпләр | Дәүләт хезмәте һаваны кондиционерлау системасы, янгынга каршы система һәм янгын сүндерү системасы, документларны рәсмиләштерү өчен кирәкле мебель, мәгълүмат стендлары белән җиһазланган биналарда һәм бүлмәләрдә күрсәтелә.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган урыннарга инвалидларның каршылыксыз үтеп керә алу мөмкинлеге тудырыла (бүлмәләргә уңайлы керү-чыгу һәм аның чикләрендә хәрәкәт итү). Дәүләт хезмәте күрсәтү турында визуаль, текстлы һәм мультимедияле мәгълүмат мөрәҗәгать итүчеләр өчен уңайлы урыннарда, шул исәптән инвалидларның чикләнгән мөмкинлекләрен исәпкә алып, урнаштырыла |
| 2.15. Дәүләт хезмәтенең һәркем алырлык һәм сыйфатлы булу күрсәткечләре, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә мөрәҗәгать итүченең вазыйфаи затлар белән бәйләнешкә кергән очраклары саны һәм аларның дәвамлылыгы, дәүләт хезмәтен | Дәүләт хезмәте күрсәтүнең үтемле булу күрсәткечләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт:<br>документларны кабул итү, тапшыру эшләре башкарыла торган биналарның җәмәгать транспортыннан файдалана алу зонасында урнашуы;<br>кирәкле санда белгечләр, шулай ук мөрәҗәгать итүчеләрдән документлар кабул итү гамәлгә ашырыла торган урыннар булуы; |

| | |
|---|---|
| дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәкләрендә, дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәкләренең читтән торып эшләү урыннарында алу мөмкинлеге, дәүләт хезмәте күрсәтү барышы турында мәгълүмат алу мөмкинлеге, шул исәптән мәгълүмат-коммуникация технологияләреннән файдаланып | дәүләт хезмәте күрсәтү ысуллары, тәртибе һәм вакытлары турында мәгълүмат стендларында, «Интернет» челтәрендәге мәгълүмат ресурсларында, Министрлыкның рәсми сайтында тулы мәгълүмат булу;<br>электрон рәвештә гариза тапшыру мөмкинлеге;<br>мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәләрен электрон рәвештә Татарстан Республикасы Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр порталындагы шәхси кабинет аша алу мөмкинлеге;<br>дәүләт хезмәте күрсәтелә торган биналарның инвалидлар өчен үтемле булуы;<br>инвалидларга биналарның инвалидлар өчен үтемле булуын тәэмин итүгә бәйле булмаган, аларга башка затлар белән тигез дәрәҗәдә хезмәтләр алуга комачаулый торган бүтән каршылыкларны җиңүдә ярдәм күрсәтү;<br>Дәүләт хезмәте күрсәтүнең сыйфатлы булу күрсәткечләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт:<br>документларны кабул итү һәм карау чорлары саклану;<br>дәүләт хезмәте нәтиҗәсен алу чоры саклану;<br>дәүләт хезмәтен күрсәтү мәсьәләсе буенча нигезле шикаятьләрнең булмавы;<br>мөрәҗәгать итүченең Министрлык белгечләре белән хезмәттәшлек итү саны:<br>дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле гариза белән документларны тапшырганда һәм дәүләт хезмәте |

| | |
|---|---|
| | нәтиҗәсен алганда, турыдан-туры – ике мәртәбәдән артык түгел (консультацияләрне исәпкә алмыйча);<br>дәүләт хезмәтен алу өчен кирәкле гариза белән документларны почта аша җибәргәндә – юк (консультацияләрне исәпкә алмыйча);<br>дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны Татарстан Республикасының Дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр порталындагы шәхси кабинет аша җибәргәндә:<br>1. әгәр дә гариза белән документларның күчермәләре 63-ФЗ номерлы федераль закон һәм 210-ФЗ номерлы федераль закон таләпләре нигезендә электрон имза белән имзаланган (таныкланган) электрон документлар рәвешендә җибәрелсә, – турыдан-туры хезмәттәшлек итү таләп ителми;<br>2. әгәр гариза белән документларның күчермәләре 63-ФЗ номерлы Федераль закон һәм 210-ФЗ номерлы Федераль закон таләпләре нигезендә электрон имза белән имзаланмаган (таныкланмаган) электрон документлар рәвешендә җибәрелсә, – бер мәртәбәдән артык түгел.<br>Мөрәҗәгать итүче белән бер мәртәбә эшләү озынлыгы – 15 минуттан артык түгел.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтү, дәүләт хезмәте күрсәтүгә гариза тапшыруны да кертеп, күпфункцияле үзәктә, күпфункцияле үзәкнең читтән торып эшләү урыннарында гамәлгә ашырылмый.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтү барышы турында мәгълүмат мөрәҗәгать итүче тарафыннан |

| | |
|---|---|
| | http://www.eco.tatarstan.ru сайтыннан, Дәүләт хезмәтләренең һәм муниципаль хезмәтләрнең бердәм порталыннан алынырга мөмкин |
| 2.16. Дәүләт хезмәтен электрон рәвештә күрсәтү үзенчәлекләре | Дәүләт хезмәтен күрсәтү турындагы гариза белән сканер аша чыгарылган документларны электрон рәвештә, алга таба рөхсәт алганда документларның төп нөсхәләрен күрсәтеп, Татарстан Республикасының Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр порталы (http://uslugi.tatarstan.ru) аша тапшыру мөмкинлеге бар |

## 3. АДМИНИСТРАТИВ ПРОЦЕДУРАЛАРНЫҢ (ГАМӘЛЛӘРНЕҢ) СОСТАВЫ, ЭЗЛЕКЛЕЛЕГЕ ҺӘМ СРОКЛАРЫ, АЛАРНЫ ҮТӘҮ ТӘРТИБЕНӘ КАРАТА ТАЛӘПЛӘР, ШУЛ ИСӘПТӘН АДМИНИСТРАТИВ ПРОЦЕДУРАЛАРНЫ (ГАМӘЛЛӘРНЕ) ЭЛЕКТРОН РӘВЕШТӘ БАШКАРУ ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ, ШУЛАЙ УК АДМИНИСТРАТИВ ПРОЦЕДУРАЛАРНЫ ДӘҮЛӘТ ХЕЗМӘТЛӘРЕ ҺӘМ МУНИЦИПАЛЬ ХЕЗМӘТЛӘР КҮРСӘТҮНЕҢ КҮПФУНКЦИЯЛЕ ҮЗӘГЕ, ДӘҮЛӘТ ХЕЗМӘТЛӘРЕ ҺӘМ МУНИЦИПАЛЬ ХЕЗМӘТЛӘР КҮРСӘТҮНЕҢ КҮПФУНКЦИЯЛЕ ҮЗӘГЕНЕҢ ЧИТТӘН ТОРЫП ЭШЛӘҮ УРЫННАРЫНДА БАШКАРУ ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ

3.1. Дәүләт хезмәтен күрсәткәндә гамәлләрнең эзлеклелегенә тасвирлама.

3.1.1. Дәүләт хезмәтен күрсәтү түбәндәге процедураларны үз эченә ала:

1) мөрәҗәгать итүчене консультацияләү, аңа ярдәм күрсәтү, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү буенча кирәкле документларны рәсмиләштерү өлешендә;

2) гаризаны һәм документларны кабул итү һәм теркәү;

3) ведомствоара гарызнамәләр формалаштыру һәм дәүләт хезмәтен күрсәтүдә катнашучы органнарга җибәрү;

4) мөрәҗәгать итүче материалларының комплектлылыгын тикшерү, мөрәҗәгать итүченең материалларын карау;

5) җир кишәрлеген авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрдән башка категориягә күчерүне килештерү турында (килештерүдән баш тарту турында) бәяләмә әзерләү;

6) мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте нәтиҗәсен бирү;

7) техник хатаны төзәтү;

3.1.2. Дәүләт хезмәтен күрсәтү буенча гамәлләрнең эзлеклелеге турында блок-схема әлеге Регламентның 6 нче кушымтасында күрсәтелде.

3.2. Мөрәҗәгать итүчене консультацияләү һәм мөрәҗәгать итүчегә ярдәм күрсәтү.

Мөрәҗәгать итүче Министрлыкның җир ресурсларын саклау бүлегенә (алга таба – Бүлек) шәхсән, почта аша, телефоннан, Татарстан Республикасының Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр порталы, Дәүләт хезмәтләренең һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) бердәм порталы аша һәм (яки) электрон почта ярдәмендә дәүләт хезмәтен алу тәртибе турында консультация алу өчен мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

Бүлек белгече шәхсән, телефоннан, электрон почта һәм (яки) хат белән, Татарстан Республикасының Дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша, мөрәҗәгать итүченең мөрәҗәгать итү ысулына карап, мөрәҗәгать итүчене консультацияли, шул исәптән гаризаның рәвеше һәм эчтәлеге буенча һәм мөрәҗәгать итүчегә ярдәм күрсәтә, шул исәптән аны рәсмиләштерү өлешендә.

Шушы пунктта билгеләнә торган процедура мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгать иткән көндә башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: гаризаның рәвеше буенча һәм дәүләт хезмәтен алу өчен башка мәсьәләләрдә консультацияләү, шулай ук мөрәҗәгать итүчегә ярдәм күрсәтү.

3.3. Җир кишәрлеген авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрдән башка категориягә күчерүне килештерү турында (килештерүдән баш тарту турында) бәяләмә бирү.

3.3.1. Гариза мөрәҗәгать итүче (вәкаләтле вәкил) тарафыннан әлеге Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документларны теркәп, шәхсән тапшырыла, яисә почта аша җибәрелә, яисә Дәүләт хезмәтләренең һәм муниципаль хезмәтләрнең бердәм порталы аша бирелә.

Җир кишәрлеген бирү шартлары әлеге Регламентка 2 нче кушымтада китерелде.

Шушы пунктта билгеләнә торган процедура гариза кергән көндә башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: тапшырылган гариза һәм документлар.

3.3.2. Документлар үтәлешен тикшерүдә тоту бүлеге белгече түбәндәгеләрне гамәлгә ашыра:

гариза белән документларны кабул итә;

гаризаны гаризаларны теркәү дәфтәрендә терки (электрон рәвештә);

мөрәҗәгать итүчегә (вәкаләтле вәкилгә) документларны кабул итү көне, ае, елы, беркетелгән кереш номеры турында тамга куеп, гариза күчермәсен тапшыра;

гаризаны һәм документларны карауны оештыру өчен Бүлек башлыгына тапшыра.

Шушы пунктта билгеләнә торган процедуралар гариза кергән көндә башкарыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: кабул ителгән, теркәлгән, Бүлек башлыгына тапшырылган документлар.

3.3.3. Бүлек башлыгы гаризаны һәм документларны карау өчен җаваплы башкаручы (алга таба – Бүлек белгече) билгели һәм тиешле карар кабул итү өчен тапшырылган материалларны аңа тапшыра.

Әлеге пунктчада билгеләнә торган процедура гариза кергән көндә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: Бүлек белгеченә тапшырылган документлар.

3.3.4. Бүлек белгече ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы (алга таба – ВЭХС) ярдәмендә электрон рәвештә түбәндәгеләргә гарызнамәләр җибәрүне гамәлгә ашыра:

Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенә – Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрыннан җир кишәрлегенә өземтә бирү турында;

мәнфәгатьле җирле үзидарә органнарына – җир кишәрлеген бирүне алдан килештерү турында (әгәр җир кишәрлеге дәүләт мөлкәтендә яисә муниципаль мөлкәттә торган җирләрдән җир кишәрлеген оештыру яки аның чикләрен ачыклау зарурлыгы булганда Россия Федерациясе Җир кодексының 39.15 статьясының 1 пунктының 6 пунктчасында күрсәтелгән нигезләр буенча бирелгән очракта), кәгазьдә әзерләнгән җир кишәрлегенең урнашу схемасы теркәп, әгәр җир кишәрлеген төзергә кирәк булса һәм мондый җир кишәрлеген оештыру күздә тотылган чикләрдәге территорияне межалау проекты булмаса;

Татарстан Республикасының Биологик ресурслар буенча дәүләт комитетына – җир кишәрлегендә төбәк әһәмиятендәге махсус саклана торган табигать

территорияләре һәм дәүләт табигый аучылык тыюлыклары булуы турында мәгълүмат бирү турында.

Җир кишәрлеген җир асты байлыкларыннан файдалану максатларында күчерү очрагында:

Җир асты байлыкларыннан файдалану департаментының Татарстан Республикасы буенча геология һәм лицензияләү бүлегенә – җир асты байлыкларыннан файдалануга лицензия бирү турында;

Экологик, технологик һәм атом күзәтчелеге буенча федераль хезмәтнең Идел буе идарәсенә (Ростехнадзор) – план-картографик материалга бүлеп бирелгән тау чикләрне төшереп (терәк, параметр, структур, эзләнү, бәяләү һәм разведка скважиналарын урнаштырудан тыш), тау бүлеп бирү актын бирү хакында.

Шулай ук электрон формада гарызнамәләр формалаштыру һәм түбәндәгеләргә җибәрү гамәлгә ашырыла:

Министрлыкның территориаль идарәләренә (алга таба – ТИ) – тиешле бәяләмәне әзерләп, җир кишәрлеген тикшерү буенча эшләр уздыру турында;

Министрлыкның минерал-чимал һәм су ресурслары идарәсенә – разведкаланган һәм территориаль баланста исәпләнүче Татарстан Республикасы каты файдалы казылма запаслары, гомумтаралган файдалы казылма яткылыклары, җир асты сулары һәм эчә торган су белән тәэмин итү чыганаклары запаслары булуы турында мәгълүмат алу өчен.

Шушы пунктта билгеләнә торган процедуралар гариза кергән көндә башкарыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: белешмәләр бирү турындагы гарызнамәләр.

3.3.5. Белешмәләр белән тәэмин итүче белгечләр ВЭХС аша килгән гарызнамәләр нигезендә сорала торган документларны (мәгълүматларны) законнарда билгеләнгән тәртиптә бирәләр.

Министрлыкның ТИ белгече урынга чыга, табигать комплексыннан аны алу мөмкинлеген билгеләү һәм күздә тотылучы максатчан билгеләнеше буенча фпйдалану өчен җир кишәрлегенә тикшерү уздыра. Урынга чыгу нәтиҗәләре буенча министрның беренче урынбасары адресына тиешле бәяләмә әзерли.

Процедураларның нәтиҗәсе: гарызнамәгә җавап нәтиҗәсе булган белешмәләр (документлар) яисә соралучы белешмәләрнең булмавы турында Министрлыкка җибәрелгән хәбәр.

3.3.6. Бүлек белгече:

ВЭХС аша алынган мәгълүматлар нигезендә җир кишәрлеген авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрдән башка категориягә күчерүне килештерүдән баш тарту өчен әлеге Регламентның 3 нче кушымтасында күрсәтелгән нигезләр булу-булмавын тикшерә;

җир кишәрлеген авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрдән башка категориягә күчерүне килештерү турында (килештерүдән баш тарту турында) бәяләмә проектын (алга таба – бәяләмә проекты) әзерли һәм аны Бүлек башлыгына килештерү өчен җибәрә;

Процедураларның нәтиҗәсе: Бүлек башлыгына килештерү өчен җибәрелгән бәяләмә проекты.

3.3.7. Бүлек башлыгы бәяләмә проектын карый, аны килештерә һәм каты файдалы казылмалар геологиясе бүлеге җитәкчесенә җибәрә.

Процедураларның нәтиҗәсе: Бүлек башлыгы тарафыннан килештерелгән һәм каты файдалы казылмалар геологиясе бүлеге башлыгына юлланган бәяләмә проекты.

3.3.8. Каты файдалы казылмалар геологиясе бүлеге башлыгы бәяләмә проектын карый, аны килештерә һәм хокукый тәэмин итү бүлеге башлыгына җибәрә.

Процедураларның нәтиҗәсе: каты файдалы казылмалар геологиясе бүлеге башлыгы тарафыннан килештерелгән һәм хокукый тәэмин итү бүлеге башлыгына юлланган бәяләмә проекты.

3.3.9. Хокукый тәэмин итү бүлеге башлыгы бәяләмә проектын карый, аны килештерә һәм минерал-чимал һәм су ресурслары идарәсе башлыгына җибәрә.

Процедураларның нәтиҗәсе: хокукый тәэмин итү бүлеге башлыгы тарафыннан килештерелгән һәм минерал-чимал һәм су ресурслары идарәсе башлыгына юлланган бәяләмә проекты.

3.3.10. Минерал-чимал һәм су ресурслары идарәсе башлыгы бәяләмә проектын карый, аны килештерә һәм әйләнә-тирә мохитне саклау идарәсе башлыгына җибәрә.

Процедураларның нәтиҗәсе: минерал-чимал һәм су ресурслары идарәсе башлыгы тарафыннан килештерелгән һәм әйләнә-тирә мохитне саклау идарәсе башлыгына юлланган бәяләмә проекты.

3.3.11. Әйләнә-тирә мохитне саклау идарәсе башлыгы бәяләмә проектын карый, аны килештерә һәм җир асты байлыкларыннан файдалану мәсьәләләре буенча җаваплы министр урынбасарына җибәрә.

Процедураларның нәтиҗәсе: әйләнә-тирә мохитне саклау идарәсе башлыгы тарафыннан килештерелгән һәм җир асты байлыкларыннан файдалану мәсьәләләре буенча җаваплы министр урынбасарына юнәлтелгән бәяләмә проекты.

3.3.12. Җир асты байлыкларыннан файдалану мәсьәләләре буенча җаваплы министр урынбасары бәяләмә проектын карый, аны килештерә һәм министрның беренче урынбасарына имзалау өчен җибәрә.

Процедураларның нәтиҗәсе: җир асты байлыкларыннан файдалану мәсьәләләре өчен җаваплы министр урынбасары тарафыннан килештерелгән һәм министрның беренче урынбасарына имзалау өчен юнәлдерелгән бәяләмә проекты.

3.3.13. Министрның беренче урынбасары бәяләмә проектын имзалый һәм аны документлар үтәлешен контрольдә тоту бүлегенә җибәрә.

Әлеге Регламентның 3.3.6-3.3.12 пунктчаларында билгеләнгән процедуралар әлеге Регламентның 3.3.5 пунктында каралган процедура тәмамланганнан соң бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: җир кишәрлеген авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрдән башка категориягә күчерүне килештерү турында (килештерүдән баш тарту турында) бәяләмәгә имза салу һәм аны документлар контрольдә тоту бүлегенә җибәрү.

3.3.14. Документлар үтәлешен тикшерүдә тоту бүлеге белгече:

җир кишәрлеген авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрдән башка категориягә күчерүне килештерү турында (килештерүдән баш тарту турында)

бәяләмәне «Электрон Хөкүмәт» Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының электрон документлар әйләнеше буенча бердәм ведомствоара системасында терки һәм аны гаризада күрсәтелгән ысул белән мөрәҗәгать итүчегә (вәкаләтле вәкилгә) җибәрә.

Әлеге пунктчада билгеләнә торган процедуралар бәяләмәгә кул куелган көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: теркәлгән һәм мөрәҗәгать итүчегә (вәкаләтле вәкилгә) бирелгән (җибәрелгән) бәяләмә.

3.4. Техник хаталарны (язу, басма хатаны, грамматик яки арифметик хатаны) төзәтү

3.4.1. Дәүләт хезмәтенең нәтиҗәсе булган документта техник хата (язу, хәреф хаталары, грамматик яки арифметик хата) ачыкланган очракта, мөрәҗәгать итүче Бүлеккә түбәндәгеләрне тапшыра:

техник хатаны (язу, хәреф хаталарын, грамматик яки арифметик хаталарны) төзәтү турында гариза (әлеге Регламентка 4 нче кушымта);

мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте нәтиҗәсе буларак бирелгән, техник хатасы (язу, хәреф хаталары, грамматик яки арифметик хаталары) булган документ;

техник хатасы (язу, хәреф хаталары, грамматик яки арифметик хатасы) барлыгын дәлилли торган, юридик көчкә ия булган документлар.

Дәүләт хезмәтенең нәтиҗәсе булган документта күрсәтелгән белешмәләрдәге техник хатаны (язу, хәреф хаталарын, грамматик яки арифметик хатаны) төзәтү турында гариза мөрәҗәгать итүче (вәкаләтле вәкил) тарафыннан шәхсән тапшырыла яисә почта аша (шул исәптән электрон почта ярдәмендә), яисә Дәүләт хезмәтләренең һәм муниципаль хезмәтләрнең бердәм порталы аша җибәрелә.

3.4.2. Министрлыкның документларны кабул итү өчен җаваплы белгече техник хатаны (язу, хәреф хаталарын, грамматик яки арифметик хатаны) төзәтү турында гаризаны кабул итә, гаризаны теркәлгән документлары белән бергә бердәм ведомствоара электрон документлар әйләнеше системасы аша электрон рәвештә терки.

Шушы пунктта билгеләнә торган процедура гариза кергән көндә башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: кабул ителгән һәм теркәлгән, карап тикшерү өчен җибәрелгән гариза.

3.4.3. Бүлек белгече документларны карап тикшерә һәм дәүләт хезмәтенең нәтиҗәсе булган документка үзгәрешләр кертү максатларында үзгәртеп рәсмиләштерелгән документны мөрәҗәгать итүчегә (вәкаләтле вәкилгә) шәхсән имзалатып, мөрәҗәгать итүчедән (вәкаләтле вәкилдән) техник хатасы (язу, хәреф хатасы, грамматик яки арифметик хатасы) булган документның төп нөсхәсен алып калып тапшыра яки мөрәҗәгать итүченең адресына почта (электрон почта) аша Бүлеккә техник хатасы (язу, хәреф хатасы, грамматик яки арифметик хатасы) булган документның төп нөсхәсен тапшырган очракта документ алу мөмкинлеге турында хат җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура техник хата (язу, хәреф хаталары, грамматик яки арифметик хата) ачыкланганнан соң яки теләсә нинди кызыксынган заттан җибәрелгән техник хатасы (язу, хәреф хаталары, грамматик яки арифметик хатасы) турында гариза алынганнан соң өч көн дәвамында башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: мөрәҗәгать итүчегә тапшырылган (җибәрелгән) документ.

3.5. Дәүләт хезмәтен күпфункцияле үзәк, КФҮ читтән торып эшләү урыны аша күрсәтү тәртибе.

Дәүләт хезмәте (дәүләт хезмәтен күрсәтү турында гариза тапшыру эшләре) күпфункцияле үзәктә, КФҮ читтән торып эшләү урыннарында күрсәтелми.

## 4. ДӘҮЛӘТ ХЕЗМӘТЕ КҮРСӘТҮНЕ ТИКШЕРЕП ТОРУ ТӘРТИБЕ ҺӘМ РӘВЕШЛӘРЕ

4.1. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең тулы һәм сыйфатлы булу-булмавын тикшереп тору түбәндәгеләрне үз эченә ала: Мөрәҗәгать итүчеләрнең хокуклары бозылуны ачыклау һәм бетерү, шикаятьләр карау, тикшерүләр уздыру, Мөрәҗәгать итүчеләрнең мөрәҗәгатьләре буенча карарлар кабул итү һәм җаваплар әзерләү, Министрлыкның вазыйфаи затлары гамәлләренә (гамәл кылмавына) карарлар әзерләү.

Административ процедураларның үтәлешен тикшереп тору рәвешләре булып түбәндәгеләр тора:

- дәүләт хезмәтен күрсәтү буенча документларның проектларына экспертиза уздыру. Экспертизаның нәтиҗәсе булып проектларга имза салу тора;

- эш алып барылышына карата билгеләнгән тәртиптә уздырыла торган тикшерү;

- билгеләнгән тәртиптә контроль тикшерүләр уздыру.

Тикшерүләр планлы һәм планнан тыш булырга мөмкин. Планлы тикшерүләр Министрлык эшенең ярты еллык һәм еллык планнары нигезендә гамәлгә ашырыла. Планнан тыш тикшерүләр мөрәҗәгать итүченең конкрет мөрәҗәгате буенча уздырыла.

Әлеге Регламентның 3 бүлегендә билгеләнгән административ процедуралар башкарылуны тикшереп тору максатларында, дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә һәм карарлар кабул ителгәндә министрга дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләре турында белешмә бирелә.

4.2. ДӘүләт хезмәтен күрсәтү буенча административ процедураларда билгеләнгән гамәлләрнең эзлеклелеге саклануы буенча агымдагы контрольлек Бүлек башлыгы тарафыннан гамәлгә ашырыла.

4.3. Әлеге Регламент үтәлешен тикшерүдә тотучы вазыйфаи затларның исемлеге Министрлык бүлекләре турында нигезләмәләрдә һәм вазыйфаи регламентларда билгеләнә.

Күрсәтелгән тикшерүдә тотуны гамәлгә ашыру ешлыгын министр билгели.

Уздырылган тикшерүләр нәтиҗәсендә мөрәҗәгать итүчеләрнең хокуклары бозылу очраклары ачыкланганда гаепле затлар Россия Федерациясе законнары нигезендә җаваплылыкка тартыла.

4.4. Министр (министрның беренче урынбасары) мөрәҗәгать итүчеләрнең мөрәҗәгатьләре вакытында каралуын тикшерүдә тота.

4.5. Гражданнар, аларның берләшмәләре һәм оешмалары тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтелүне контрольлектә тоту дәүләт хезмәтен күрсәткәндә Министрлык

эшчәнлегенең ачык булуы, дәүләт хезмәтен күрсәтү тәртибе турында актуаль һәм төгәл мәгълүматны алу һәм дәүләт хезмәтен күрсәтү процессында мөрәҗәгатьләрне (шикаятьләрне) судка кадәр тәртиптә карап тикшерү мөмкинлеге аша гамәлгә ашырыла.

## 5. ДӘҮЛӘТ ХЕЗМӘТЕН КҮРСӘТҮЧЕ ОРГАННЫҢ, ШУЛАЙ УК ВАЗЫЙФАИ ЗАТЛАРНЫҢ, ДӘҮЛӘТ ХЕЗМӘТКӘРЛӘРЕНЕҢ КАРАРЛАРЫНА ҺӘМ ГАМӘЛЛӘРЕНӘ (ГАМӘЛ КЫЛМАВЫНА) СУДКА КАДӘР (СУДТАН ТЫШ) ШИКАЯТЬ БЕЛДЕРҮ ТӘРТИБЕ

5.1. Мөрәҗәгать итүчеләр дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы Министрлыкның, Министрлык вазыйфаи затының яисә дәүләт граждан хезмәткәренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять белдерергә хокуклы, судка кадәр тәртиптә – Министрлыкка. Дәүләт хезмәте күрсәтелүгә бәйле рәвештә министр карарларына, гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаятьләр мөрәҗәгать итүче тарафыннан Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына тапшырыла.

Мөрәҗәгать итүчеләр түбәндәге очракларда шикаять белән мөрәҗәгать белән мөрәҗәгать итә ала:

1) дәүләт хезмәте күрсәтү турында гарызнамәне теркәү чоры бозылганда;

2) дәүләт хезмәте күрсәтү чоры бозылганда;

3) мөрәҗәгать итүчедән Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен тапшырылуы яки гамәлгә ашырылуы каралмаган документларны яки мәгълүматларны тапшыру яисә гамәлләр башкару таләп ителгәндә;

4) дәүләт хезмәте күрсәтү буенча тапшырылырга тиешле, Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында каралган документларны мөрәҗәгать итүчедән кабул итеп алудан баш тартылганда;

5) дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тартканда, әгәр федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең бүтән норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы законнарында һәм бүтән норматив хокукый актларында баш тарту нигезләре каралмаган булса;

6) дәүләт хезмәтен күрсәткәндә мөрәҗәгать итүчедән Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында каралмаган түләү таләп ителгәндә;

7) дәүләт хезмәтен күрсәтүче органның, әлеге органдагы вазыйфаи затның дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәсендә тапшырылган документларда җибәрелгән хаталарны яки ялгышларны төзәтүдән баш тартуы яисә мондый төзәтүләрнең билгеләнгән вакыты бозылган очракта;

8) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләре буенча документларны бирү срогы яисә тәртибе бозылганда;

9) дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып торганда, әгәр федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең бүтән норматив хокукый

актларында, Татарстан Республикасы законнарында һәм норматив хокукый актларында туктатып тору өчен нигезләр каралмаган булса;

10) дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән яки дәүләт хезмәте күрсәтүдән беренче мәртәбә баш тартканда, 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы федераль законның 7 статьясының 1 өлешендәге 4 пунктында каралганнардан тыш, булмавы һәм (яки) дөрес булмавы турында күрсәтелмәгән документлар яки мәгълүмат таләп ителгәндә.

5.2. Шикаять кәгазьдә язмача яки электрон рәвештә тапшырыла.

Дәүләт хезмәтен алучылар тарафыннан шикаять почта белән, күпфункцияле үзәк аша, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәреннән файдаланып, Министрлыкның рәсми сайтыннан (http://eco.tatarstan.ru), Татарстан Республикасы Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр порталыннан (https://uslugi.tatarstan.ru), Дәүләт хезмәтләренең һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) бердәм порталыннан (https://www.gosuslugi.ru/) җибәрелергә, шулай ук мөрәҗәгать итүчене шәхсән кабул иткәндә кабул итеп алынырга мөмкин.

5.3. Шикаятьтә түбәндәгеләр булырга тиеш:

карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять белдерелгән дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче органдагы вазыйфаи затның яки граждан хезмәткәренең аталышы;

мөрәҗәгать итүче – физик затның фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта), яшәгән урыны турында белешмәләр, мөрәҗәгать итүче – юридик затның урнашкан урыны турында белешмәләр, шулай ук элемтә телефоны номеры (номерлары), электрон почта адресы (адреслары) (булган очракта) һәм мөрәҗәгать итүчегә җавап җибәрелергә мөмкин булган почта адресы;

дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче органдагы вазыйфаи затның яки дәүләт хезмәткәренең шикаять белдерелгән карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмавы) турында мәгълүматлар;

мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәтен күрсәтүче органның, дәүләт хезмәтен күрсәтүче органдагы вазыйфаи затның яисә дәүләт хезмәткәренең карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмавы) белән ризалашмавын нигезләүче дәлилләр. Мөрәҗәгать итүче тарафыннан мөрәҗәгать итүченең дәлилләрен раслый торган документлар (булган очракта) яки аларның күчермәләре тапшырылырга мөмкин.

5.4. Шикаятьне карау чоры – аны теркәүгә алганнан соңгы 15 эш көне эчендә. Дәүләт хезмәтен күрсәтүче органның мөрәҗәгать итүчедән документларны кабул итүдән баш тартуына яисә җибәрелгән хаталарны һәм ялгышларны төзәтүдән баш тартуына шикаять белдерелгәндә яисә мондый төзәтмәләр кертүнең билгеләнгән вакыты бозылган очракта, – аны теркәүгә алганнан соңгы 5 эш көне эчендә.

5.5. Шикаятьне карау нәтиҗәләре буенча түбәндәге карарларның берсе кабул ителә:

1) шикаять канәгатьләндерелә, шул исәптән кабул ителгән карарны гамәлдән чыгару, дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда җибәрелгән язу һәм басма хаталарны төзәтү, мөрәҗәгать итүчегә Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында алуы каралмаган түләүләрне кайтарып бирү рәвешендә;

2) шикаятьне канәгатьләндерүдән баш тартыла.

Шушы пунктта күрсәтелгән карарны кабул иткән көннән соң бер көн узганчы мөрәҗәгать итүчегә язмача яисә аның ихтыяры буенча электрон рәвештә шикаятьне карап тикшерү нәтиҗәләре турында нигезләнгән хат җибәрелә.

Шикаять канәгатьләндерелергә тиеш дип танылган очракта, җавапта мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәтен күрсәткәндә ачыкланган җитешсезлекләрне кичекмәстән юк итү максатларында дәүләт хезмәтен күрсәтүче орган тарафыннан гамәлгә ашырыла торган гамәлләр турында мәгълүмат бирелә, шулай ук китерелгән уңайсызлыклар өчен гафу үтенелә һәм дәүләт хезмәтен алу максатларында алга таба мөрәҗәгать итүче эшләргә тиешле гамәлләр турында мәгълүмат күрсәтелә.

5.6. Шикаять канәгатьләндерергә тиешле түгел дип танылган очракта мөрәҗәгать итүчегә җавапта кабул ителгән карарның сәбәпләре турында нигезле аңламтамалар, шулай ук кабул ителгән карарга шикаять белдерү тәртибе турында мәгълүмат күрсәтелә.

5.7. Шикаятьне карап тикшерү барышында яисә нәтиҗәсендә административ хокук бозу яки җинаять билгеләре ачыкланган очракта, шикаятьләрне карап тикшерү вәкаләте бирелгән вазыйфаи зат булган материалларны кичекмәстән прокуратура органнарына җибәрә.

Җир кишәрлеген авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрдән башка категориягә күчерүне килештерү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 1 нче кушымта

КИҢӘШ ИТЕЛӘ ТОРГАН РӘВЕШЕ

Татарстан Республикасы экология һәм табигать ресурслары министрына

____________________________________

Кемнән: ______________________________

(шәхси эшкуарлар өчен: Ф.И.А.,адресы (почта һәм (яисә) электрон)

____________________________________

юридик затлар өчен: оешма аталышы, адресЫ (почта һәм (яки) электрон)

Авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрдән җир кишәрлеген башка категориягә күчерү турында гариза

___________________________________________________________________ үтенә

(гражданинның фамилиясе, исеме, атасының исеме яки юридик затның исеме)

җир кишәрлеген авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрдән күчерүне гамәлгә ашыру турында

мәйданы мәйданы___________________________________________________ гектар

кадастр номеры_____________________________________________________,

______________________________________________________________хокукында

(гамәлдәге хокук атамасы)

______________________________________________________идарәсендә булган

(җирдән файдаланучының исеме)

Татарстан Республикасының _______________________ районы территориясендә,

(муниципаль район атамасы)

җирләрнең _________________________________________________категориясенә

(җирләрнең җир кишәрлеген күчерү планлаштырыла торган

__________________________________________________________________________

категориясе күрсәтелә)

___________________________________________________________________ өчен.

(максатчан билгеләнеше)

Күчерүне нигезләү: расланган территориаль планлаштыру документына туры килә _____________________________________________

(муниципаль берәмлек советы карарының реквизитлары

__________________________________________________________________________

территориаль планлаштыру документын раслау турында, территориаль планлаштыруның расланган документларына үзгәрешләр кертү хакында (булган очракта))

| | |
|---|---|
| Мөрәҗәгать итүченең почта адресы | |
| | |
| Элемтә өчен телефоны | |

Әлеге үтенеч язуына исемлеккә туры китереп, документлар теркәлә.
Мөрәҗәгать итүче(ләр)нең, ышаныч кәгазе буенча вәкил(ләр)нең имзасы:
«__» _________ № __________.
_____________________________________________________ / ___________________/
(мөрәҗәгать итүченең (вәкилнең) фамилиясе, исеме, атасының исеме) (имза)
М.У. <*>

--------------------------------

<*> Россия Федерациясе законнарында мөһергә ия булу йөкләмәсе билгеләнгән очракларда

Җир кишәрлеген авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрдән башка категориягә күчерүне килештерү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 2 нче кушымта

Җир кишәрлеген бирү шартлары

1. Гамәлдәге законнарда каралган очракларда дәүләт экологик экспертизасының уңай бәяләмәсен алу (174-ФЗ номерлы Федераль законның 11, 12 статьялары).

2. Капиталь төзелеш объектларының проект документларына уңай дәүләт экспертизасы бәяләмәсен алу (РФ Шәһәр төзелеше кодексының 49 статьясы).

3. Җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалануга бәйле эшләрне башкару өчен файдалы казылма ятмаларын эшкәртүнең техник проектларын билгеләнгән тәртиптә килештерүләр (2395-1 номерлы РФ Законының 23 статьясы, РФ Хөкүмәтенең 118 номерлы карары).

4. Җир асты суларын саклауга карата гомуми таләпләрне (ГОСТ 17.1.3.06-82), җир асты суларын пычранудан саклауга гигиеник таләпләрне (СП 2.1.5.1059-01) үтәү (РФ Законының 23 статьясындагы 8, 11 пунктлары, РФ Хөкүмәтенең 94 номерлы карары).

5. Җир эшләрен башкарганда туфракның уңдырышлы катламын саклауга карата таләпләрне үтәү (ГОСТ 17.4.3.02-85).

6. Бозылган җирләрне рекультивацияләү (ГОСТ 17.5.3.04-83, РФ Хөкүмәтенең 800 номерлы карары) һәм билгеләнгән срокларда рөхсәтле файдалану өчен яраклы хәлдә җирдән файдаланучыларга тапшыру (РФ Җир кодексының 13, 42 статьялары).

7. Әйләнә-тирә мохитне саклау, табигый объектларны торгызу, табигый ресурслардан рациональ файдалану буенча чаралар комплексын үткәрү (7-ФЗ номерлы федераль законның 34 статьясы).

8. Җирләрнең һәм туфракларның пычрануын, ярлылануын, деградацияләнүен, бозылуын, юкка чыгуын, хуҗалык һәм башка төр эшчәнлек нәтиҗәсендә башка тискәре йогынтыларны булдырмый торган чаралар комплексын, шулай ук туфракларның уңдырышлылыгын арттыруга юнәлдерелгән чараларны уздыру (Россия Федерациясе Җир кодексының 12, 42 статьялары).

9. РФ Су кодексының 6, 65 статьялары таләпләре нигезендә яр буе полосаларында, яр буенча саклык полосаларында, су саклау зоналарында җирләрдән файдалану режимын үтәү.

10. Хайваннар дөньясы объектларының тереклек итү тирәлеген һәм аларның үрчү, май җыю, ял итү шартларын һәм миграцияләү юлларын саклау, шулай ук яклана торган кишәрлекләрнең һәм акваторияләрнең кагылгысызлыгын тәэмин итү буенча чаралар уздыру (1995 елның 24 апрелендәге 52-ФЗ номерлы Федераль законның 22 статьясы, РФ Хөкүмәтенең 997 номерлы карары, ТР МКның 669 номерлы карары).

11. Территорияләрне төзекләндерү һәм яшелләндерү чараларын үткәрү (7-ФЗ

номерлы Федераль законның 44 статьясы, СП 42.13330.2016 9 бүлеге).

12. Радиоактив матдәләрне җитештергәндә, саклаганда, транспорт белән күчергәндә, кулланганда һәм күмгәндә 7-ФЗ номерлы Федераль законның 48 статьясының 1 пункты таләпләрен үтәү.

13. Җитештерү һәм куллану калдыкларын, радиоактив калдыкларны җыю, туплау, утильләштерү, зарарсызландыру, транспорт белән күчерү, саклау һәм күмү таләпләрен үтәү (7-ФЗ номерлы Федераль законның 51 статьясы, 1999 елның 30 мартындагы 52-ФЗ номерлы Федераль законның 22 статьясы).

14. Җир асты байлыклары кишәрлегенең ярашлылыгын билгеләү буенча таләпләрне үтәү (2395-1 номерлы РФ Законының 19 статьясы, 1722-XII номерлы ТР Законының 29 статьясы, ТР Министрлар Кабинетының 171 номерлы карарының 3 пункты) (шәхси ихтыяҗлар өчен гомумтаралган файдалы казылмалар чыгарылганда, җир асты корылмалары төзелгәндә һәм көнкүреш коелары һәм скважиналары урнаштырылганда).

15. Җир асты байлыкларыннан файдалану нияте турында Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы хәбәре буенча таләпләрне үтәү (2395-1 номерлы РФ Законының 19, 19.1 статьялары, 2395-1 номерлы ТР Законының 29 статьясы, 1722-XII номерлы ТР Министрлар Кабинеты Карарының 5 пункты, 171 номерлы ТР Министрлар Кабинеты Карарының 5 пункты) (тау бүлеп бирелгән чикләрендә гомумтаралган файдалы казылмалар чыгарылган очракта).

16. Мотор ягулыгы парларын тоту һәм рекуперацияләү системалары белән резервуарларны һәм ягулык тарату колонкаларын җиһазлау буенча күрсәтмә (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 152-р номерлы күрсәтмәсе, РД 153-39.2-080-01 18.2 пункты)(автотәэмин итү станцияләрен урнаштырганда).

Җир кишәрлеген авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрдән башка категориягә күчерүне килештерү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 3 нче кушымта

Җир кишәрлеген авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрдән башка категориягә күчерүдән баш тарту нигезләре

1. Шушы Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документлар исемлегендә күрсәтелгән документның тапшырылмавы.

2. Федераль мөлкәттә торган объектлар биләгән җир кишәрлекләрен тартып алу (РФ Җир кодексының 27 статьясындагы 4 пункты);

3. Дәүләт мөлкәтендә һәм муниципаль мөлкәттә торган җир кишәрлекләрен әйләнешендә чикләү (РФ Җир кодексының 27 статьясындагы 5 пункты):

– РФ Җир кодексының 27 статьясындагы 4 пунктында күрсәтелмәгән, махсус сакланыла торган табигать территорияләре чикләрендә;

– урман фонды җирләре составыннан;

– чикләрендә дәүләт мөлкәтендә яки муниципаль мөлкәттә торган су объектлары урнашкан;

– гидротехник корылма объектлары астында урнашкан;

– агулы матдәләр җитештерү өчен тапшырылган;

– хәтәр калдыклар, радиоактив матдәләр белән пычранган, биоген пычрануга дучар ителгән, җир дегарадацияләренә дучар ителгән бүтән җирләр;

– эчә торган һәм хуҗалык-көнкүрештә су белән тәэмин итү чыганакларының санитар саклык зоналарының беренче һәм икенче поясларында.

4. Әлеге җирләрнең төп билгеләнешенә туры килми торган максатлар өчен җир кишәрлекләрен җир категорияләре составыннан алуны тыю:

– махсус сакланыла торган табигать территорияләре, шул исәптән махсус сакланыла торган табигать территорияләре өчен резервланган (РФ Җир кодексының 95 статьясындагы 3, 5, 7 пунктлары, 7-ФЗ номерлы Федераль законның 58 статьясының 4 пункты, 59 статьясының 2 пункты, 33-ФЗ номерлы Федераль законның 9 статьясының 1 пункты, 21 статьясының 4 пункты, 24 статьясының 1 пункты, 27 статьясының 1 пункты, 29 статьясының 1 пункты);

– сирәк һәм юкка чыгу куркынычы янаган туфраклары булган кишәрлекләр (7-ФЗ номерлы Федераль законның 62 статьясы);

– кадастр бәясе муниципаль район (шәһәр округы) буенча уртача кадастр бәясе дәрәҗәсеннән шактый артып китә торган аеруча кыйммәтле продуктив авыл хуҗалыгы биләмәләре (РФ Җир кодексының 79 статьясының 4 пункты);

– сирәк һәм юкка чыгу куркынычы янаган хайван һәм үсемлек төрләренең тереклек итү һәм үсеш алу урыннары (7-ФЗ номерлы Федераль законның 60 статьясы);

– дәвалау-сәламәтләндерү урыннары һәм курортлар (РФ Җир кодексының 96 статьясының 3 пункты, 26-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясының 3

пункты);

– яклагыч урманнар били торган (урман фонды җирләрендә, махсус сакланыла торган территорияләр җирләрендә урнашкан яклагыч урманнардан тыш) (РФ Җир кодексының 97 статьясы, РФ Урман кодексының 10 статьясы, 12 статьясының 4 пункты, 102 статьясының 2, 5 пунктлары);

– рекреацион билгеләнешле (РФ Җир кодексының 98 статьясы 5 пункты);

– аеруча кыйммәтле җирләр (РФ Җир кодексының 100 статьясы 1 пункты);

– гомуми файдаланудагы су объектларының яр буе полосалары, су саклау зоналары һәм яр буе саклык полосалары территорияләре (РФ Су кодексының 6, 65 статьялары);

– су фонды (РФ Җир кодексының 102 статьясының 2 пункты);

– җирлекләрнең яшел фонд объектлары (7-ФЗ номерлы Федераль законның 61 статьясының 2 пункты, СП 42.13330.2016);

– су белән тәэмин итү чыганакларын, җир асты суларын санитар саклау зоналарын (СанПиН 2.1.4.1110-02, СП 2.1.5.1059-01);

– шәһәр һәм авыл җирлекләренең яшел зоналары (7-ФЗ номерлы Федераль законның 61 статьясы, СП 42.13330.2016);

– гомуми файдаланудагы (РФ Җир кодексының 85 статьясындагы 12 пункты);

– автомобиль юлларын аерып чыгару полосалары (РФ Җир кодексының 90 статьясындагы 3 пункты).

5. Җир асты байлыкларыннан файдалануны чикләү (2395-1 номерлы РФ Законының 8 статьясы).

6. Җиргә хокукларны чикләү (РФ Җир кодексының 56 статьясы):

– территорияләрдән файдалануда махсус шартлары булган зоналарда җир кишәрлекләреннән файдалануны чикләү;

– әйләнә-тирә мохитне, шул исәптән хайваннар һәм үсемлекләр дөньясын саклауның, туфракның уңдырышлы катламын, кыргый хайваннарның табигый яшәү тирәлеген, миграцияләү юлларын саклауның махсус шартлары.

Җир кишәрлеген авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрдән башка категориягә күчерүне килештерү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 4 нче кушымта

КИҢӘШ ИТЕЛӘ ТОРГАН РӘВЕШЕ

Татарстан Республикасы экология һәм табигать ресурслары министрына

______________________________________

Кемнән: _________________________________

(шәхси эшкуарлар өчен:
Ф.И.А.,адресы (почта һәм (яисә) электрон)
______________________________________
юридик затлар өчен: оешма аталышы,
адресЫ (почта һәм (яки) электрон)

Техник хаталарны (язу, басма хаталарын, грамматик яки арифметик хаталарны) төзәтү турында гариза

Дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә җибәрелгән хата (язу, басма хаталары, грамматик яисә арифметик хаталар) турында хәбәр итәм

________________________________________________________________________

(дәүләт хезмәтенең аталышы)

Язылган: ______________________________________________________________

________________________________________________________________________

Дөрес белешмәләр: ________________________________________________

________________________________________________________________________

Җибәрелгән техник хатаны (язу, басма хаталарын, грамматик яисә арифметик хаталарны) төзәтүне һәм дәүләт хезмәте нәтиҗәсе булган документка тиешле үзгәрешләр кертүне сорыйм.

Түбәндәге документларны терким:

1.

2.

3.

Техник хатаны (язу, басма хаталарын, грамматик яисә арифметик хаталарны) төзәтү турында гаризаны кире кагу турында карар кабул ителгән очракта мондый карарны түбәндәгечә җибәрүне сорыйм:

e-mail:____________________________ адресына электрон документ рәвешендә;

________________________;

___________________________________________________________ адресы буенча кәгазьдәге документның таныкланган күчермәсе рәвешендә.

Шәхси белешмәләрне эшкәртүгә, шул исәптән автоматлаштырылган режимда, алар нигезендә дәүләт хезмәтен күрсәтүче орган тарафыннан дәүләт хезмәтен күрсәтү максатларында карарлар кабул итүне кертеп, (шәхси белешмәләрне җыюга, системага салуга, туплауга, саклауга, тәгаенләүгә(яңартуга, үзгәртүгә), файдалануга, таратуга (шул исәптән тапшыруга), шәхси үзенчәлекләрен бетерүгә, ябуга, юкка чыгаруга, шулай ук дәүләт хезмәтен күрсәтү кысаларында шәхси белешмәләрне эшкәртү өчен кирәкле булган башка төрле гамәлләргә) үземнең ризалыгымны, минем тарафтан вәкил булган затның ризалыгын раслыйм.

Хәзергесе белән шунысын раслыйм: гаризага кертелгән, минем шәхесемә һәм минем тарафтан вәкил булган затка кагыла торган, шулай ук минем тарафтан түбәндә кертелгән белешмәләр дөрес. Гаризага теркәлгән документлар (документларның күчермәләре) Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән таләпләргә җавап бирә, гаризаны тапшыру вакытына бу документлар гамәлдә һәм төгәл мәгълүматларны үз эченә ала.

Миңа күрсәтелгән дәүләт хезмәтенең сыйфатын бәяләү буенча түбәндәге телефон аша сораштыруда катнашуга ризалыгымны бирәм: _____________.

____________________ _____________ (______________________)
(дата) (имза) (Ф.И.А.).

Җир кишәрлеген авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрдән башка категориягә күчерүне килештерү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 5 нче кушымта

# ДӘҮЛӘТ ХЕЗМӘТЕН КҮРСӘТҮ ӨЧЕН ҖАВАПЛЫ БУЛГАН ҺӘМ АНЫҢ ҮТӘЛЕШЕН ТИКШЕРҮДӘ ТОТУНЫ ГАМӘЛГӘ АШЫРУЧЫ ОРГАННАР ҺӘМ ВАЗЫЙФАИ ЗАТЛАР ТУРЫНДА БЕЛЕШМӘЛӘР

Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы


| Вазыйфа | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|
| министр | 267-68-01 | eco@tatar.ru. |
| Министрның беренче урынбасары | 267-68-19 | Fayaz.Shakirov@tatar.ru |
| Әйләнә-тирә мохитне саклау идарәсе башлыгы | 267-68-30 | Albert.Shubin@tatar.ru |
| Җир ресурсларын саклау бүлеге башлыгы | 267-68-36 | L.Mubarakshina@tatar.ru |
| Эш башкару бүлеге башлыгы | 267-68-04<br>267-68-05 | eco@tatar.ru. |

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты

| Вазыйфа | Телефон | Электрон адресы |
|---|---|---|
| Җир асты биләмәләреннән, табигать ресурсларынан файдалану һәм әйләнә-тирә мохитне саклау мәсьәләләре бүлеге башлыгы | 264-77-78 | Marat.Fashutdinov@tatar.ru |

Җир кишәрлеген авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрдән башка категориягә күчерүне килештерү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 6 нчы кушымта

# ДӘҮЛӘТ ХЕЗМӘТЕН КҮРСӘТКӘНДӘ ГАМӘЛЛӘРНЕҢ ЭЗЛЕКЛЕЛЕГЕ БУЕНЧА БЛОК-СХЕМА



Бүлек белгече

Документларны тикшерә → Тикшерелгән документлар

Бүлек белгече

Җир кишәрлеген авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрдән башка категориягә күчерүне килештерү турында (килештерүдән баш тарту турында) бәяләмә проектын (алга таба – бәяләмә проекты) әзерли → Бәяләмә проекты

Бүлек башлыгы

Бәяләмә проектын карый, аны килештерә → Килештерелгән бәяләмә проекты

Каты файдалы казылмалар геологиясе бүлеге башлыгы

Бәяләмә проектын карый, аны килештерә → Килештерелгән бәяләмә проекты

Хокукый тәэминат бүлеге башлыгы

Бәяләмә проектын карый, аны килештерә → Килештерелгән бәяләмә проекты

Минерал-чимал һәм су ресурслары идарәсе башлыгы

Бәяләмә проектын карый, аны килештерә → Килештерелгән бәяләмә проекты

Әйләнә-тирә мохитне саклау идарәсе башлыгы

Бәяләмә проектын карый, аны килештерә → Килештерелгән бәяләмә проекты

Җир асты байлыкларыннан файдалану мәсьәләләре буенча җаваплы министр урынбасары

Бәяләмә проектын карый, аны килештерә → Килештерелгән бәяләмә проекты

Министрның беренче урынбасары

Җир кишәрлеген авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрдән башка категориягә күчерүне килештерү турында (килештерүдән баш тарту турында) бәяләмәне имзалый → Имзаланган бәяләмә

Документлар үтәлешен тикшерүдә тоту бүлеге белгече

Бәяләмәне терки һәм гариза бирүчегә җибәрә → Гариза бирүчегә җибәрелгән бәяләмә